| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 07 » 11 2019 № 764

Аксубаево

2020 елга «Аксубай муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү
оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 10 декабрендәге 326 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга кушымталарны расларга:

- «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм интернат мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар.

2. Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасы тарафыннан расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә тиеш:

- «2020 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән»;

- әлеге карарның 1 пункты белән.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм милек белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.и. Моратшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган
07.11.2019 № 764

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм интернат мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар бер тәрбияләнүчегә, елга сум . |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы Интернат | шәһәр җирлеге | 90980 |
| | авыл җирлеге | 92342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 137238 |
| | авыл җирлеге | 141713 |